| СОВЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сабакайка авыл торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2025 елның 25 октябреннән № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 18 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сабакайка авыл торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2026 елда Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сабакайка авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәреннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан, 18 яшькә кадәрге 3 баласы булган гаиләләрдән тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, үзагымлы изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, автоматлар, контактторлар сатып алу һәм урнаштыру.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия ясалган очракта Алексеевск шәһәр җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.»

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен,Сабакайка авылы мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Татарстан Республикасы Алексеевск**
**муниципаль районының «Алексеевск**
**шәһәр җирлеге» муниципаль**
**берәмлеге Башлыгы** **С.А. Демидов**